| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2026 ел Алабуга шәһәре № 42

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турында» 2012 елның 14 декабрендәге 272 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2012 елның 14 декабрендәге 272 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районының бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмә тексты буенча «Алабуга муниципаль районының хокукый палатасы» сүзләрен тиешле килешләрдә «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 17 нче статьяның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) касса планын төзү һәм алып бару тәртибен, шулай ук бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторлары тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләр составын һәм аларны тапшыру срокларын билгеләү;

1.3. 29 статьяның 9 өлеше үз көчен югалткан дип танырга.

15. 51 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты район бюджеты турында Совет карары проектын Алабуга муниципаль районы Советына карауга керткән көннән алып ике эш көне эчендә Алабуга муниципаль районы Советы рәисе аны

Советның бюджет мәсьәләләре буенча эшләүче органнарына – Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризмга ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссиягә карарга, бәяләмә бирү өчен Алабуга муниципаль районының Контроль-хисап палатасына, шулай ук Алабуга муниципаль районы Советы депутатларына җибәрә».

1.5. 51 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Район бюджеты турындагы карар проекты Алабуга муниципаль районы Советы тарафыннан мәсьәләләрне чираттан тыш карау буенча Алабуга муниципаль районы Советы эш планына кертелә. Район бюджеты турында карар бер укылышта кабул ителә.».

1.6. 55 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Районның финанс-бюджет палатасы касса планын төзү һәм алып бару тәртибен, шулай ук бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторлары тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләр составын һәм аларны тапшыру срокларын билгели.».

1.7. 59 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерациясе законнары нигезендә Федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары (җирле бюджетлардан) бюджетлардан акча алучыларның вакытлыча карамагына керә торган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән очракларда һәм тәртиптә кире кайтарылырга яисә күчерелергә тиешле акчалар белән операцияләрне исәпкә алу, әлеге акчалар Федераль казначылык органнары тарафыннан ачыкланмаган керемнәргә кертелгән һәм тиешле казначылык счетларында исәпкә алынган очрактан тыш, тиешенчә Федераль казначылыкта, Россия Федерациясе субъектының (муниципаль берәмлекнең)финанс органында ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.».

2. Әлеге карарның 1.3 пункты 2026 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте һәм эшкуарлыкка ярдәм мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов